МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___30.11.2023___ Казан ш. №_912од______________

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы» 24.10.2017 № 925 од Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРАМ:

1.«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 24.10.2017 № 925 од Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгына (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 07.12.2021 № 1016/1 од, 05.05.2022 № 304 од боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турындагы» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына ярашлы рәвештә БОЕРАМ:»;

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында боерык белән расланган Нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлыгына, дәүләт комитетына» ведомствосына» дигән сүзләрне «республика башкарма хакимият органына» дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.»;

3.1 пунктта «министрлыкка, дәүләт комитетына, Татарстан Республикасы ведомствосына» дигән сүзләрне «республика башкарма хакимият органына» дигән сүзләр белән алыштырырга;

3.8 пункт түбәндәге эчтәлектә:

«3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Министрлык боерыгына ярашлы рәвештә Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме нигезендә, шулай ук әлеге Положениенең 3.7 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта башкарыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә 3.7 пунктының дүртенче, бишенче, унынчы — уникенче абзацларында каралган хәлләрнең килеп чыгуы турында хәбәр итәргә тиеш» дигәнне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Министрлык боерыгына ярашлы рәвештә Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме нигезендә, шулай ук әлеге Положениенең 3.7 пунктында каралган шартлар ачыкланган очракта башкарыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә 3.8 пунктның дүртенче, бишенче, унынчы — уникенче абзацларында каралган хәлләрнең килеп чыгуы турында хәбәр итәргә тиеш»;

5.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга, «бу башкарма хакимият органнары янында» сүзләрен «бу республика башкарма хакимият органнары янында» сүзләре белән алыштырырга.

Министр И.Х.Әюпова